**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт бүләкләрен бирү системасын камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында» 1993 елның 16 апрелендәге ПУ-206 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 1999 елның 9 мартындагы ПУ-147 номерлы, 2000 елның 13 декабрендәге ПУ-979 номерлы, 2001 елның 6 апрелендәге ПУ-265 номерлы, 2005 елның 24 декабрендәге ПУ-514 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-129 номерлы, 2007 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2008 елның 20 мартындагы ПУ-120 номерлы һәм 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1232 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «һәрберсе 300 мең сум» сүзләрен «һәрберсе биш йөз мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

б) Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре турында нигезләмәнең 7 пунктында «һәрберсе 300 мең сум» сүзләрен «һәрберсе биш йөз мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны үтәүне тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2014 ел, 09 декабрь
№ ПУ-1120